**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
МАЛОКИБЯКОЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Малая, 10, село Малые Кибя-Кози,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: **Mbiz.Tul @tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ КИБӘХУҖА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**

Кече урам, 10, Кече Кибәхуҗа авылы,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: Mbiz.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318079 ОГРН 1061675010451 ИНН/КПП 1619004429/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№10** **13 август 2020ел**

Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Кече Кибәхуҗа ав., 26 йорт, Кече ур., Җаваплылыгы чикләнгән “Игенче” ширкате бинасында мәгълүмат стенды;

- Олы Кибәхуҗа ав., 8 йорт, Г.Сөләйманов ур. Олы Кибәхуҗа мәдәният йорты бинасындагы мәгълүмат стенды;

- Казаклар ав., 9 йорт, Тау асты ур., Казаклар авыл клубы бинасындагы мәгълүмат стенды.

2. Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә алтынчы

чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июль №3 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча: Кече Кибәхуҗа ав., 10 йорт, Кече ур., Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе И.Г.Заһидуллин